**ОКТЯБРЬ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**КАРАР**

«15» февраль 2019 № 195

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Октябрь авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Октябрь авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына, Октябрь авыл җирлеге Советына таянып, Октябрь авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Октябрь авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.
2. Үз көчен югалткан дип танырга:

- Зеленодольск муниципаль районы Октябрь авыл җирлеге Советының 2014 елның 25 июлендәге 167 номерлы «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Октябрь авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» карары;
- Зеленодольск муниципаль районы Октябрь авыл җирлеге Советының 2017 елның 15 декабрендәге 124 номерлы «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Октябрь авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» карары;
- Зеленодольск муниципаль районы Октябрь авыл җирлеге Советының 2018 елның 12 июлендә кабул ителгән 157 номерлы «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Октябрь авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» карары;

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Зеленодольск муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча: Татарстан Республикасы, Зеленодольск районы, Октябрьский поселогы, Первомайский урамы, 14а йорт (авыл мәдәният йорты бинасы); Татарстан Республикасы, Зеленодольск районы, Октябрьский поселогы, Первомайская урамы, 2 йорт (авыл җирлеге башкарма комитеты бинасы).
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам

**Октябрь авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **А.П. Дементьев**